СОВЕТ
МАРСОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МАРС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

422472 с. Нижний Каракитан, ул. Ленина, 30 тел. (84375) 31-1-36

Р Е Ш Е Н И Е КАРАР

с.Нижний Каракитан

2019 елның 18 апреле № 44/1

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Марс авыл җирлеге Советының " Физик затларның милкенә салым турында «2014 елның 18 ноябрендәге 45/1 номерлы карарының 2.3 пунктына үзгәрешләр кертү хакында»

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, Россия Федерациясе Бюджет Кодексының 64 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Марс авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Марс авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1.Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Марс авыл җирлеге Советының «Физик затларның милкенә салым турында» 18.11.2014 ел, № 45/1 карарының 2.3 пунктына (советның 2015 елның 27 апрелендәге 53/2 номерлы, 2015 елның 14 октябрендәге 2/1 номерлы, 2015 елның 18 декабрендәге 54/2 номерлы, 2018 елның 24 августындагы 29а/1 номерлы, 2018 елның 26 октябрендәге, 34 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), яңа редакциядә бәян итеп, түбәндәге үзгәрешләрне кертергә: "Салымнар һәм җыемнар турындагы законнарда билгеләнгән салым ташламаларына хокукы булган физик затлар салым органына салым ташламаларын бирү турындагы гаризаны үз теләге белән тапшыра, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслаучы документларны тапшырырга хокуклы.».

2. Бу карарны Марс авыл җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Марс авыл җирлеге башлыгы: Җамалетдинов Р.М.